**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 13 маендагы 1637 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 4 апрелендәге 2103 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьяларына туры китереп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 августындагы 3670 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 4 апрелендәге 2103 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр әзерләү турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 4 апрелендәге 2103 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясен планлаштыру проектына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 22 июнендәге 3629 номерлы, 2020 елның 29 октябрендәге 3049 номерлы, 2021 елның 25 февралендәге 459 номерлы, 2022 елның 31 октябрендәге 3710 номерлы, 2024 елның 14 июнендәге 2494 номерлы, 2025 елның 8 апрелендәге 1065 номерлы, 2026 елның

6 апрелендәге 1090 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарга кушымта нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат органнарының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 13 маендагы
1637 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2012 елның 4 апрелендәге 2103 номерлы карары**
**белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясен**
**планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән төзелеш тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль хезмәт, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмәдәге «Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү һәм социаль хезмәт күрсәтү системасы характеристикалары» дигән 1 бүлектә:

1.1. «“Седьмое небо” торак районы территориясенең планлаштыру структурасы» дигән 1.2 пунктта уналтынчы абзацны «иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы (планлаштырыла торган)» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. «Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү һәм социаль хезмәт күрсәтү системасы характеристикалары» дигән 1.3 пунктта:

1.2.1. 1.3.1 пунктчадагы 1 таблицада:

1.2.1.1. 12 нче юлда «19 411*» санын «19 711» санына алыштырырга;

1.2.1.2. 12.11 нче юлда «5 327» санын «5 354» санына алыштырырга;

1.2.1.3. 12.12 нче юлда «2 367» санын «2 340» санына алыштырырга;

1.2.1.4. түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| № т/б | Атамасы | Билгеләнеше | Объектлар саны | Куәте | Микрорайон номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| «12.13 | Паркинг | ОД-2 | 1 | 300 машина урыны | 3» |

1.2.1.5. 1 таблицага искәрмәне төшереп калдырырга;

1.2.1.6. 1 таблицадан соң түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Күпкатлы паркингларны чиратлап, шулай ук торак төзелешенең планлаштырыла торган чиратлары нигезендә төзү күздә тотыла. Барлык паркинглар төзелгәнче, машина урыннарының исәпләнгән санының бер өлеше шул исәптән вакытлыча яссы парковкалар оештыру юлы белән тәэмин ителергә мөмкин:

- Ж-1А (М-1 микрорайонында гомуми сыйдырышлылыгы 696 машина урыны булган ПК-1): ОП-5 М-4А (ПК-3) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр – 25 машина урыны, ОП-4 М-4 (ПК1-1) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 671 машина урыны яссы парковкалар рәвешендә вакытлыча түбәндәгечә урнаштырылачак: 367 машина урыны – өлешчә М-2 микрорайоны территориясендә (ПК-1 территориясендәге Ж-1Б зонасы), 329 машина урыны – өлешчә М-4А микрорайоны территориясендә (ПК-1 технопаркы территориясендәге ОП-4 зонасы);

- Ж-1А (М-1 микрорайонында гомуми сыйдырышлылыгы 207 машина урыны булган ПК-3): ОП-4 М-4 (ПК1-2) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 207 машина урыны вакытлыча М-2 микрорайоны территориясендә (ПК-1 территориясендәге Ж-1Б зонасы) яссы парковкалар рәвешендә урнаштырылачак;

- Ж-1А (М-1 микрорайонында гомуми сыйдырышлылыгы 110 машина урыны булган ПК-4): ОП-4 М-4 (ПК1-2) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 110 машина урыны вакытлыча М-4 микрорайоны территориясендә (ПК-1 технопаркы территориясендәге ОП-4 зонасы) яссы парковкалар рәвешендә урнаштырылачак;

- Ж-1А (М-1 микрорайонында гомуми сыйдырышлылыгы 265 машина урыны булган ПК-5): ОП-4 М-4 (ПК1-1) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 265 машина урыны вакытлыча М-4 микрорайоны территориясендә (М-4 (ДК-1) микрорайонында ПК-2 мәдәни-ял итү үзәге территориясе) яссы парковкалар рәвешендә урнаштырылачак;

- Ж-1А (М-1 микрорайонында гомуми сыйдырышлылыгы 244 машина урыны булган ПК-10): ОП-4 М-4 (ПК1-1) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр – 22 машина урыны, ОП-4 М-4 (ПК1-5) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр – 128 машина урыны һәм ОП-5 М-4А (ПК-3) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 94 машина урыны вакытлыча М-4 микрорайоны территориясендә (М-4 (ДК-1) микрорайонында ПК-2 мәдәни-ял итү үзәге территориясе) яссы парковкалар рәвешендә урнаштырылачак;

- Ж-1А (М-1 микрорайонында гомуми сыйдырышлыклары 199 машина урыны, 214 машина урыны һәм 118 машина урыны булган ПК-11, ПК-12,

ПК-13): ОП-4 М-4 (ПК1-2) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 531 машина урыны вакытлыча М-2 микрорайоны территориясендә (ПК-1 территориясендәге Ж-1Б зонасы) яссы парковкалар рәвешендә урнаштырылачак;

- Ж-1А (М-1 микрорайонында гомуми сыйдырышлылыгы 108 машина урыны булган ПК-14): ОП-4 М-4 (ПК1-2) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 108 машина урыны яссы парковкалар рәвешендә вакытлыча түбәндәгечә урнаштырылачак: 60 машина урыны – М-4 микрорайоны территориясендә (М-4 (ДК-1) микрорайонында ПК-2 мәдәни-ял итү үзәге территориясе), 48 машина урыны – ПК-1 технопаркы территориясендәге ОП-4 зонасы территориясендә;

- Ж-1Б (М-2 микрорайонында гомуми сыйдырышлыклары 164 машина урыны һәм 197 машина урыны булган ПК-2 һәм ПК-3): ОП-5 М-4А (ПК-3) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 361 машина урыны вакытлыча М-3 микрорайонында паркингы булган ПК1-5 бизнес-үзәге территориясендә яссы парковкалар рәвешендә урнаштырылачак;

- Ж-1Б (М-2 микрорайонында гомуми сыйдырышлыгы 483 машина урыны булган ПК-5): ОП-5 М-4А (ПК-3) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 483 машина урыны вакытлыча М-3 (ОД-3) микрорайонындагы ПК-5 бизнес-үзәге территориясендә яссы парковкалар рәвешендә урнаштырылачак;

- Ж-1В (М-3 микрорайонында гомуми сыйдырышлыклары 355 машина урыны һәм 150 машина урыны булган ПК-1 һәм ПК-3): ОП-4 М-4 (ПК1-3) микрорайонында һәм М-3 (ПК1-5 БЦ) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 505 машина урыны яссы парковкалар рәвешендә вакытлыча түбәндәгечә урнаштырылачак: 340 машина урыны – 4А номерлы микрорайон территориясендәге ОП-5 (ПК-3 – паркинг), З-2 (ПК-1 – ССМП), ОД-4 (ПК-5 – БЦ) зоналарында, 165 машина урыны – М-3 (ОД-3) микрорайонындагы ПК-5 бизнес-үзәге территориясендә;

- Ж-1Г (М-4 микрорайонында гомуми сыйдырышлыклары 302 машина урыны һәм 201 машина урыны булган ПК-6 һәм ПК-7): ОП-4 М-4 (ПК1-3) микрорайонында паркинг төзелгәнчегә кадәр 503 машина урыны вакытлыча 4А номерлы микрорайон территориясендәге ОП-5 (ПК-3 – паркинг), З-2 (ПК-1 – ССМП), ОД-4 (ПК-5 – БЦ) зоналарында яссы парковкалар рәвешендә урнаштырылачак.

Паркинглар төзелгәнчегә кадәр төзелеш алып барылмый торган территорияләрдә территорияне планлаштыру проекты чикләрендә 569 машина урынына, 702 машина урынына, 843 машина урынына, 648 машина урынына, 1105 машина урынына, 366 машина урынына исәпләнгән алты вакытлыча

парковка оештыру планлаштырыла (үзгәрешләр булган очракта, машина урыннарын вакытлыча урнаштыру әлеге территориядә төзелеш алып барылмавын нигезләү юлы белән һәм территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертмичә генә төзелеш эскизына төзәтмәләр кертү юлы белән мөмкин булачак).

Ж-1А (М-1 микрорайонындагы ПК-11) өчен исәпләнгән машина урыннары санының бер өлеше – 46 машина урыны эшләп килүче мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе белән чиктәш җир кишәрлеге чикләрендә урнашкан (М-1 микрорайонындагы ПК-2).

Ж-1А (М-1 микрорайонындагы ПК-12) өчен исәпләнгән машина урыннары санының бер өлеше – 19 машина урыны эшләп килүче мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе белән чиктәш җир кишәрлеге чикләрендә урнашкан (М-1 микрорайонындагы ПК-2).

Соңгы паркингны файдалануга тапшыру вакыты соңгы торак йортны файдалануга тапшыру срогыннан да соңрак була алмый.

Машина урыннарының исәпләнгән саны парковка урыннарын оештыру өчен билгеләнгән территорияләрдә планлаштыру проекты чикләрендә урнаштырылган [урнаштыру ысулы һәм урыны проектлаштыруның алдагы стадияләрендә аныклана (ачык парковкалар, һәм/яки җир өсте паркинглары, һәм/яки җир асты паркинглары, һәм/яки гараж-машина кую объектлары, һәм/яки стилобатлар)]. Фатирлар саны, торак фонды мәйданы, күпфатирлы торак йортларда эчкә кертеп төзелгән, эчкә кертеп-кушып төзелгән торак булмаган билгеләнештәге биналар мәйданы, административ-эшлекле, сәүдә һәм иҗтимагый билгеләнештәге объектлар мәйданы кимегән очракта, машина урыннары саны һәм паркингларның (җир өсте һәм җир асты) сыйдырышлылыгы территорияне планлаштыруның әлеге проекты белән каралган нормативлар нигезендә фатирлар санының, мәйданнарның факттагы күрсәткечләреннән чыгып кими.

**Сызымда күрсәтелми»;

1.2.2. 1.3.2 пунктчада:

1.2.2.1. 2 таблицада:

1.2.2.1.1. 3 нче юлда «1 666» санын «1 966» санына алыштырырга;

1.2.2.1.2. «БАРЛЫГЫ» юлында «17 956» санын «18 256» санына алыштырырга;

1.2.2.2. 3 таблицада:

1.2.2.2.1. 3 нче юлда «1 666» санын «1 966» санына алыштырырга;

1.2.2.2.2. «БАРЛЫГЫ» юлында «16 259» санын «16 559» санына алыштырырга;

1.2.2.3. 3 таблицадан соң:

1.2.2.3.1. беренче абзацта түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга:

«Алга таба проектлаштырганда һәр җир кишәрлеге өчен торак фондының тыгызлыгы «Торак биналар һәм корылмалар исемлеге», «Торак булмаган биналар һәм корылмалар исемлеге» таблицалары күрсәткечләре, нигезләү материаллары буенча исәпләнә»;

1.2.2.3.2. түбәндәге эчтәлекле абзацлар һәм таблица өстәргә:

«Торак фондының, торак булмаган билгеләнештәге эчкә кертеп, кушып, эчкә кертеп-кушып төзелгән, аерым торучы биналарның мәйданы кимегән очракта, ихтыяҗ күрсәткечләре әлеге планлаштыру проектына салынган нормативлар нигезендә мәйданнарның факттагы күрсәткечләреннән чыгып кими.

Этап эчендә мәйданнарның (торак һәм торак булмаган, шул исәптән эчкә кертеп, эчкә кертеп-кушып төзелгән торак булмаган биналар арасында) сан ягыннан характеристикалары җир кишәрлекләре/эшләтеп җибәрү комплекслары арасында пропорциональ рәвештә үзгәртелергә мөмкин, әмма алар үзләштерүнең тиешле этабы өчен территоияне планлаштыру проекты белән билгеләнгән максималь күрсәткечтән артмаска тиеш.

Иҗтимагый-торак, административ-эшлекле, иҗтимагый һәм сәүдә-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру зоналарын, иҗтимагый-эшлекле (планлаштырыла торган), иҗтимагый-җитештерү, уку-укыту һәм белем бирү билгеләнешендәге объектларны урнаштыру зоналарын, шулай ук гомуми файдаланудагы территорияләрне үз эченә алган планлаштыру проекты чикләрендә торак фондының исәпләнгән тыгызлыгы Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә 7 521,9 кв.м/га тәшкил итә. Бу күрсәткеч Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 27 статьясындагы 6 таблица белән билгеләнгән торак фонды тыгызлыгының максималь күрсәткеченнән артмый.

Алга таба проектлаштырганда төзелешнең һәр этабындагы җир кишәрлекләре өчен җир кишәрлегенең торак фонды тыгызлыгы әлеге планлаштыру проекты белән кабул ителгән параметрлар нигезендә исәпләнә. Шуңа бәйле рәвештә М-1, М-2, М-3, М-4 микрорайоннарында иҗтимагый-торак билгеләнешендәге объектлар зонасының җир кишәрлекләре/эшләтеп җибәрү комплекслары өчен торак фондының (һәрбер җир кишәрлегенең/эшләтеп җибәрү комплексының) максималь тыгызлыгы 25 000 кв.м/га итеп алына.

Төзелеш проценты, беренче катны иҗтимагый-эшлекле функция өчен файдалануның минималь проценты 4 таблица нигезендә билгеләнә.

*4 таблица*

**Билгеләнә торган чик параметрлар**

| Капиталь төзелеш объектларының атамасы | Чик параметрлар | |
|---|---|---|
| | Төзелеш проценты (торак өлеше/стилобат буенча), % | Иҗтимагый функция өчен файдаланыла торган, кызыл линияләр яки төзелешне җайга салу линияләре белән билгеләнгән гомуми файдаланудагы территориягә чыгучы беренче кат фасады озынлыгының, минималь проценты, % |
| ПК3 (М-1) | 80/билгеләнмәгән* | 30 |
| ПК13 (М-1) | 80/билгеләнмәгән* | 30 |
| ПК1 (М-2) | 80/билгеләнмәгән* | 30 |
| ПК1 (М-3) | 80/билгеләнмәгән* | 30 |
| ПК3 (М-3) | 80/билгеләнмәгән* | 30 |
| ПК6 (М-4) | 80/билгеләнмәгән* | 30 |
| ПК7 (М-4) | 80/билгеләнмәгән* | 30 |

* «билгеләнмәгән*» – параметрлар Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә билгеләнә.

М-1, М-2, М-3, М-4, М-4А микрорайоннарындагы иҗтимагый-җитештерү билгеләнешендәге, административ-эшлекле, иҗтимагый һәм сәүдә-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар зоналары, иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны (планлаштырыла торган) урнаштыру зоналары өчен торак булмаган объектларны (һәрбер җир кишәрлегенең/эшләтеп җибәрү комплексының) төзү процентын түбәндәгечә билгеләргә:

- рөхсәт ителгән файдалануның тиешле төре өчен җир кишәрлеген төзү проценты – 90%;

- стилобатны төзү проценты – 90%»;

1.3. «Транспорт хезмәте күрсәтү системасын үстерү характеристикалары» дигән 1.4 пунктның 7 пунктчасында «23 479» санын «23 779» санына, «13 694» санын «13 994» санына алыштырырга;

1.4. «Инженерлык-техник яктан тәэмин итү системасын үстерү характеристикалары» дигән 1.5 пунктта:

1.4.1. 1.5.1 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Проектлаштырыла торган бизнес-үзәк һәм паркинг территориясе өчен хуҗалыкта һәм эчү өчен файдаланыла торган суның чыгымы тәүлегенә 36,82 куб.м тәшкил итә.

Проектлаштырыла торган бизнес-үзәк һәм паркинг территориясен су белән тәэмин итү өчен Җиңү проспектында урнашкан гамәлдәге Ø315 мм суүткәргечтән суүткәргеч челтәрләре төзү күздә тотыла.

Проектлаштырыла торган челтәрләренең гомуми озынлыгы – 0,11 км»;

1.4.2. 1.5.2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Проектлаштырыла торган бизнес-үзәк һәм паркинг өчен агынты суларның тәүлеклек чыгымы 30,82 куб.м тәшкил итәчәк.

Проектлаштырыла торган бизнес-үзәктән һәм паркингтан көнкүреш агынты суларны читкә чыгару өчен, Җиңү проспектында урнашкан гамәлдәге Ø315-400 мм канализация коллекторына тоташтырып, үзагышлы көнкүреш канализациясе челтәрләрен төзү планлаштырыла.

Проектлаштырыла торган канализация челтәрләренең гомуми озынлыгы – 0,2 км»;

1.4.3. 1.5.3 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Проектлаштырыла торган бизнес-үзәк һәм паркинг территориясеннән җир өсте суларын чыгару чыгымы секундына 57,37 л тәшкил итәчәк.

Проектта ябык Ø400 мм яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү тәкъдим ителә. Алга таба аны Җиңү проспектында проектлаштырыла торган Ø600 мм яңгыр канализациясе челтәрләренә тоташтыру каралган.

Проектлаштырыла торган яңгыр канализация челтәрләренең гомуми озынлыгы – 0,17 км»;

1.4.4. 1.5.4 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Исәпләүләр нигезендә бизнес-үзәк һәм паркинг өчен электр куллану күләме 161,79 кВт тәшкил итәчәк. Электр белән тәэмин итү яңа ТП-1 трансформатор подстанциясеннән (туклану үзәге – РП-2 – ПС Азино, проектлаштыру чикләреннән читтә урнашкан) каралган.

Территорияне төзү буенча эшләнгән планлаштыру карарларын исәпкә алып, түбәндәге чараларны башкару күздә тотыла:

- гамәлдәге ВЛ 0,4 кВ чыгару – 60 м;

- КЛ 0,4 кВ төзү (ВЛ 0,4 участогын кабельгә күчерү) – 100 м;

- гамәлдәге КЛ 10 кВ чыгару – 53 м;

- КЛ 10 кВ төзү (күчерү) – 170 м;

- гамәлдәге КЛ 0,4 кВ чыгару – 61 м;

- КЛ 0,4 кВ төзү (күчерү) – 110 м;

- яңа ТП-1 дән КЛ 0,4 кВ төзү;

- ВРУ-0,4 кВ урнаштыру;

- 0,4 кВ көчәнешле кертү-бүлеп тарату җайланмасында өч фазалы ток кабул итү җайланмалары өчен саклану рәвешендә сүндерү җайланмасы урнаштыру, аларны җиргә тоташтыру, тулы булмаган фазалы режимда эшләүдән саклау (бер фазалы ток кабул итү җайланмаларын артык көчәнештән саклау) күздә тотыла»;

1.4.5. 1.5.6 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Проектлаштырыла торган территория буенча башкарылган исәпләүләр нәтиҗәләре нигезендә бизнес-үзәк һәм паркинг өчен җылылыкка булган ихтыяҗ 1,4729 МВт (1,2665 Гкал/сәг) тәшкил итәчәк.

Җылылык белән тәэмин итүнең беренче чираты сыйфатында гамәлдәге Ø219 мм җылылык белән тәэмин итү челтәрләреннән (ТК22-27/15 җылылык камерасы) 2Ø250 мм җылылык үткәргеч төзү каралган. Җылылык үткәргечнең тоташтыру ноктасыннан гомуми озынлыгы – 350 м.

Алдагы этапларда, «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең 2025 елның 12 августындагы 102-6/4738 номерлы хаты нигезендә, бизнес-үзәк объектларын һәм паркингны җылылык белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасына тоташтыру өчен техник мөмкинлек Казан шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасы нигезендә Казан шәһәренең 1 нче җылылык электр үзәгеннән (КТЭЦ-1) «Горки» котельныена (Ø800 мм) трасса буенча 2×7800 м (15 600 м) озынлыкта 5 номерлы магистраль җылылык үткәргеч төзелгәннән соң барлыкка киләчәк. Бу шәһәрнең яңадан үзләштерелә торган районнарында перспективалы җылылык йөкләнешләрен тоташтыру өчен җылылык егәрлегенә кытлык булга зоналардан җылылык егәрлеге артык булган зоналарга җылылык йөкләнешен яңадан бүлүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Җылылык белән тәэмин итү системасы – ябык, бәйсез. Чыганактан җылылык челтәрләренең температура графигы – 150-70℃.

Бизнес-үзәк бинасында шәхси җылылык пункты урнаштыру зарур. Кайнар су белән тәэмин итү ихтыяҗлары өчен шәхси җылылык пунктларына шәхси су җылыткычлары урнаштыру мөһим.

Кайнар су белән тәэмин итү бойлерын урнаштыруга бәйле рәвештә проект белән түбәндәгеләрне башкару күздә тотыла:

- температура көйләгеч урнаштыру;

- кайнар су белән тәэмин итүнең циркуляция насосын урнаштыру.

Җылыту приборларын җылылыкны автомат рәвештә көйләүче җайланмалар (термостатлар) белән җиһазландыру зарур»;

1.4.6. 1.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле 1.5.7 пунктча өстәргә:

«1.5.7. элемтә челтәрләренә тоташу ноктасы – Казан шәһәре, Сабир Әхтәмов урамы, 1 йорт, 1 корпус ((55.788356, 49.216768) адресы буенча урнашкан йорт.

Хезмәтләргә тоташу өчен «Уфанет» АҖ мәгълүматларны җыю һәм тапшыру җайланмасында мәгълүматны 10 Гбит/с ка кадәр тизлек белән тапшыру мөмкинлеге булган порт/портлар бүлеп бирә.

Мәгълүмат тапшыру хезмәтләренә тоташтыру җепселле-оптик кабель буенча гамәлгә ашырыла. Проект белән тоташтырыла торган бинадан ерак булмаган урында кабель линиясе коесын урнаштыру, шулай ук, каналларының диаметры 63 мм булган түбән басымлы полиэтилен торбалар кулланып, кабель канализациясе төзү күздә тотыла.

Проект буенча 19" телекоммуникация шкафы урнаштыру планлаштырыла. Ул агрегация узелы өчен генә каралган. Аның үлчәмнәрен, аңарда җепселле-оптик элемтә линиясенең мәгълүматны тапшыруны яки кабул итүне тәэмин итүче җайланмаларын һәм актив җиһазлар (SFP-портлар булган коммутатор, электр белән өзлексез тәэмин итү системалары һ.б.) урнаштыруны исәпкә алып, проект белән билгеләргә.

Торак секторны кабельле телевизион тапшырулар хезмәте белән тәэмин итү өчен комплексның торак йортларында кабельле телевизион тапшыруларның оптик үзгәрткечләрен урнаштырыла торган телекоммуникация шкафларына урнаштыруны күздә тотарга кирәк».


2. Кызыл линияләр, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны һәм башка капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә кушымта нигезендә бирергә.

3. Кызыл линияләр, юлларны, урамнарны, элемтә линияләрен, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын билгели торган линияләр күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымын гамәлдән чыккан дип санарга.

______________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 4 апрелендәге 2103 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә кушымта

II. Фрагмент чертежа Проекта планировки с указанием красных линий, границ зон планируемого размещения объектов социально-культурного и коммунально-бытового назначения и иных объектов капитального строительства




| Условные обозначения: | |
|---|---|
| Границы: | |
| | граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории |
| | граница элемента планировочной структуры |
| | граница земельного участка |
| Линии градостроительного регулирования: | |
| | действующая красная линия улично-дорожной сети |
| | действующая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети) |
| | линия регулирования застройки |
| Зоны размещения: | |
| 1 | порядковый номер зоны размещения |
| 1 | вид зоны размещения объектов капитального строительства |
| 1.9 | площадь зоны размещения (га) |
| 3.5.1 | код вида разрешенного использования |
| 10.1 | максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м/га) |
| 9 | максимальная этажность (этаж) |
| н.у. | параметры (характеристика) не устанавливается |
| 5 | зона размещения объектов общественно-делового назначения (планируемая) |
| ОП-1 | номер планируемого объекта обслуживания (см. табл.) |
| Инженерное обеспечения территории: | |
| | трансформаторная подстанция (ориентировочное расположение) |
| | трансформаторная подстанция (существующая) |

Примечание : Места расположения объектов инженерной инфраструктуры являются ориентировочными и определяются на последующих стадиях проектирования

Экспликация проектируемых объектов

| Обозначен. | Вид использования | Площадь, га. |
|---|---|---|
| ОД-2 | Объекты административно-делового, общественного и торгово-бытового назначения | 0.916 |